**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 26.07.2023** **№ 984**

Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә уза торган муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкаруга чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 елның 18 мартындагы 330 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Биектау муниципаль районы территориясендә шәһәр яны муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны җайга салу һәм идарә итү системасын оештыру һәм камилләштерү, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының билгеләнгән чикләрендә транспорт хезмәтләреннән бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законына, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясына, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш), индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга, шул исәптән субсидияләр формасындагы грантларга гомуми таләпләр турында, һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карарына, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 18 мартындагы 330 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә уза торган автомобиль транспортында җайга салына торган тарифлар буенча даими

рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкаруга чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында йөртүчеләргә субсидияләр бирү буенча комиссия составы» 2 кушымтасын яңа редакциядә кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны интернет челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталының Биектау муниципаль районы рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштырып халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ җитәкчесе урынбасары М.Р. Булгаковка йөкләргә.

Җитәкче Д.Ф.Шәйдуллин

Кушымта

Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2023 елның 26.07.2023 № 984 нче номерлы карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә уза торган автомобиль транспортында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкаруга чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында йөртүчеләргә субсидияләр бирү буенча комиссия составы**

| | |
|---|---|
| 1. Булгаков Мурад Рамил улы | Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе; |
| 2. Хәкимуллин Рамил Фатыйх улы | Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Комиссия секретаре: | |
| 3. Нигъмәтуллина Айгөл Рәшит кызы | Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге башлыгы |
| Комиссия әгъзалары: | |
| 4. Хәйретдинов Наил Фидаил улы | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының контроль-хисап палатасы рәисе |
| 5. Сабирова Айгөл Илгиз кызы | «ТР БМР Советы» МБ МКУнең юридик бүлеге әйдәп баручы белгече. |